**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларына үзгәрешләр кертү турында

Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1216 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-572 номерлы, 2015 елның 23 апрелендәге ПУ-412 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге ПУ-654 номерлы, 2015 елның 15 августындагы ПУ-724 номерлы, 2016 елның 10 февралендәге ПУ-131 номерлы, 2016 елның 9 июлендәге ПУ-588 номерлы, 2017 елның 7 июлендәге ПУ-608 номерлы һәм 2018 елның 19 маендагы ПУ-381 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ау параметрларының III кисәгенә, 6 – 10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«6. 2020 елга кадәрге чорга төбәк әһәмиятендәге барлык дәүләт табигать зоология (аучылык) заказникларында һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

7. 2018 елның җәйге-көзге-кышкы ау сезонына һәм 2019 елның язгы ау сезонына «Беркут»,«Глухарь» аучылык хуҗалыклары һәм Баулы районының ачык аучылык хуҗалыкларыннан тыш, барлык аучылык биләмәләрендә суерга һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

8. 2018 елның җәйге-көзге-кышкы ау сезонына һәм 2019 елның язгы ау сезонына «Никольское», «Питрәч» аучылык хуҗалыкларыннан тыш, барлык аучылык биләмәләрендә көртлеккә һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

9. 2018 елның җәйге-көзге-кышкы ау сезонына «Азнакай», «Аксубай», «Апас», «Баиковская роща», «Барс», «Беркут», «Олы Карагуҗа», «Бөгелмә», «Буа», «Бутино-Чишмә», «Югары Ослан», «Идел», «Забава»,

«Зеленодольск», «Кайбыч», «Кама-Исмәгыйль», «Кама Тамагы» («Кама Тамагы аучылык хуҗалыгы» җирле иҗтимагый оешмасы тарафыннан файдаланыла), «Кама Тамагы» («Вепрь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан файдаланыла), «Караеш», «Куйбышев», «Ласка», «Алексеевск районы аучылар һәм балыкчылар җирле иҗтимагый оешмасы», «Мизин», «Никольское», «Питрәч», «Попов», «Сарман», «Свияжск», «Тәмте», «Тәтеш», «Урыссу», «Фазан», «Юкә» аучылык хуҗалыкларыннан һәм Азнакай, Аксубай, Алексеевск, Әлки, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Чүпрәле, Кайбыч, Зеленодольск, Сарман, Спас, Тәтеш һәм Чистай районнары ачык аучылык хуҗалыкларыннан тыш, барлык аучылык биләмәләрендә соры кыр тавыгына һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

10. 2018/2019 еллар ау сезонында «Азнакай», «Ак Барс», «Актаныш», «Әтнә», «Баганино», «Бакчасарай», «Балтач», «Берсут», «Олы Карагуҗа», «Идел», «Вятское», «Глухарь», «Дубрава», «Егерь», «Алабуга», «Забава», «Зеленодольск», «Камский берег», «Красный бор», «Красновидово», «Кызыл Октябрь», «Лубян», «Мизин», «Мөслим», «Охотничьи традиции», «Охотничьи традиции 2», «Свиногорье», «Төньяк», «Баграж», «Сухарево», «Трофей», «Уракчы», «Урыссу», «Усы», «Ширәмәт», «Чишмә», «Шуман», «Көньяк» аучылык хуҗалыкларыннан һәм Әгерҗе, Азнакай, Биектау, Алабуга, Лаеш, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Балык Бистәсе һәм Тукай районнары ачык аучылык хуҗалыкларыннан тыш, барлык аучылык биләмәләрендә соры куянга һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.».

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә.

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 30 май
№ ПУ-397